**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 31 декабрь № 1035

г. Казань

Федераль һәм республика программаларын тормышка ашыруда катнашучы социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларның республика реестры турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларга булышлык күрсәтү» ярдәмче программасын тормышка ашыру максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгын Федераль һәм республика программаларын тормышка ашыруда катнашучы социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларның республика реестрын (алга таба – Реестр) булдыруга һәм алып баруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы итеп билгеләргә.

2. Реестрны булдыру һәм алып бару максатларында Татарстан Республикасы министрлыкларына, дәүләт комитетларына һәм ведомстволарына бу карар үз көченә кергән көннән башлап:

ун көн эчендә вазыйфаларына Реестрга мәгълүмат туплау кергән җаваплы затны билгеләргә;

утыз көн эчендә 2014 – 2015 елларга мәгълүматны әлеге карарга кушымтага ярашлы рәвештә форма буенча Реестрга кертергә;

2016 елдан башлап тиешле норматив хокукый акт кабул ителгән көннән соң ун көн эчендә мәгълүматны Реестрга кертергә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына муниципаль программаларны тормышка ашыруда катнашучы

социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларның муниципаль реестрларын эшләргә тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\1035.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 31 декабрь, 1035 нче
карарына кушымта

Форма

**Федераль, республика программаларын тормышка ашыруда катнашучы Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары реестры**

| Т/с | Федераль/ республика программасы исеме | Расланган федераль/ республика программасы турында норматив хокукый акт реквизитлары | Федераль/ республика программасын тормышка ашыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы министрлыгы, ведомствосы исеме | Федераль/ республика программасын тормышка ашыруда катнашучы коммерциячел булмаган оешма исеме | Коммерциячел булмаган оешманың ИНН | Коммерциячел булмаган оешманың ОГРН | Коммерциячел булмаган оешманың элемтә өчен мәгълүматлары | | | | Коммерциячел булмаган оешма тормышка ашыра торган федераль/ республика программасы чарасы | Коммерциячел булмаган оешма тарафыннан федераль/ республика программасы чарасын тормышка ашыру өчен бүлеп бирелгән акча күләме, мең сум | Финанслау чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | почта адресы | сайт исеме (булганда) | электрон почта адресы | кодын күрсәтеп, телефоннар номерлары | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |